Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл җирлеге Советы Карары

26 август 2019 ел № 100

Күңгәр авыл җирлеге Советының 2012 елның 20 июнендәге 39 номерлы карары белән расланган Әтнә муниципаль районы «Күңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы «Мәҗбүри иминият системасында индивидуаль (персонификацияләнгән ) исәпкә алу турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә Күңгәр авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Советының 2012 елның 20 июнендәге 39 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Күңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 15 статьяның 15.3 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6) индивидуаль (персонификацияләнгән ) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында теркәлүне раслый торган документ;»

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча ) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында :(pravo.tatarstan.ru веб –адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл башлыгы Г.Х.Гарипова